# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 13 ноябрь 2020 ел

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Әлкәй авыл
жирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнардан
үзара салым кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә
Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлеге Әлкәй авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүг буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Әлкәй авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар декасы», «Яңа ел» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);
-Әлкәй авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (карны механикалаштырылган җыештыру хезмәтләре өчен түләү, чит оешмаларның юлларны кардан чистарту хезмәтләре);
территорияне төзекләндерүне оештыру (территорияне механикалаштырылган чаптыру хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, Әлкәй авылы территориясен яшелләндерү чаралары);
-җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру (парк коймалары өчен материал сатып алу);
-Әлкәй авылында һәлак булган сугышчыларга куелган һәйкәлләрне төзекләндерү (чәчәк үсентеләре сатып алу);
-халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру (Әлкәй авылында эчә торган суның биохимик һәм бактериологик анализын үткәрү);
-күмү урыннарын карап тоту (зиратларны дератизацияләү, зират коймаларын буяу өчен лаклы материаллар сатып алу);

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Әлкәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Әлкәй авыл җирлеге башлыгы С.З.Зиннурова